СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 г.Лениногорск № 75

Лениногорск муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының, «Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясы таләпләре нигезендә Лениногорск муниципаль районы Советы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыру тәртибен билгеләү максатларында КАРАР БИРДЕ:

1. Хезмәт торак урыннарын Лениногорск муниципаль районының муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге башкарма комитетын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыруга документлар кабул итү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Лениногорск
муниципаль районы
Башлыгы урынбасары С.В.Тимаков

Лениногорск муниципаль районы
Советының 2024 елның 04 октябрендәге
75 номерлы карары белән расланды

# Лениногорск муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыру тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 04 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясы таләпләре нигезендә эшләнгән һәм хезмәт торак урыннарын Лениногорск муниципаль районының муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру тәртибен регламентлаштыра.

2. Хезмәт торак урыннары муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдырылырга мөмкин:

2.1. Лениногорск муниципаль районы территориясендә теркәлгән, муниципаль махсуслаштырылган торак фонды реестрында торучы хезмәткәрләргә хезмәт торак урыннары биргән оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләренең үтенечнамәләре буенча, гражданнарның әлеге оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә хезмәт торагына наем шартнамәсе төзелгән көннән кимендә 10 ел эшләү дәвамлылыгы шарты белән;

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Лениногорск районы буенча бүлеге башлыгы, Лениногорск шәһәр прокуроры үтенечнамәләре буенча, Лениногорск муниципаль районы территориясендә муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарында яшәүче Эчке эшләр органында һәм прокуратурада 10 елдан артык хезмәт итүнең гомуми дәвамлылыгы шарты белән;

2.3. муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан үзләренә торак урыннары биргән оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә кимендә 10 ел эшләгән гражданнарның гаризалары буенча;

2.4. гражданнарның түбәндәге категорияләре гаризалары буенча, аларның эш (хезмәт)стажын исәпкә алмыйча:

- хәрби хезмәт бурычларын яисә хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (вафат булган) яисә хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрләрнең, вазыйфаи затларның, Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең һәм аларга тиңләштерелгән затларның гаилә әгъзалары;

- хезмәт урыны бирелгән һәм соңыннан вафат булган хезмәткәрнең гаилә әгъзалары;

эш бирүче гаебе белән хезмәттә гарипләнү нәтиҗәсендә инвалидлыклары башланган I яки II төркем инвалидлар;

- хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һөнәри авыру нәтиҗәсендә инвалидлыклары башланган I яки II төркем инвалидлар;

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә алган яралану, контузия яки гариплек нәтиҗәсендә йә хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын)үтәүгә бәйле авыру

аркасында I яки II төркем инвалид булган хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар арасыннан инвалидлар;

предприятие, учреждение, оешма ябылуга йә хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар;

- картлык буенча пенсионерлар;

- махсуслаштырылган торак фондының торак урыны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган «бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында» гы нигезләмә нигезендә танылган очракта.

3. Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләре һәм (яисә) гражданнар муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыру өчен Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) түбәндәге документларны тапшыралар::

- нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча гариза;

- Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) органы, Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) учреждениесе җитәкчесенен үтенечнамәсе;

- хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында кәгазьдә тиешенчә таныкланган яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә (эш бирүчедә булганда)документлар;

- хезмәт шартнамәсенең таныкланган күчермәсе йә хезмәт контрактының таныкланган күчермәсе;

- хезмәт торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар;

- мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы Документлар;

- гражданның, шулай ук балигъ булмаганнарны да кертеп, Лениногорск муниципаль районы территориясендә күчемсез мөлкәт объектларына хокукны теркәү турында соратып алына торган белешмәләрнең Бердәм дәүләт реестрында булмавы турында мөрәҗәгать итүче вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан бирелгән хәбәрнамә;

- Дәүләт техник исәпкә алуы һәм (яисә) техник инвентаризация буенча вәкаләтле оешманың 2000 елның 1 гыйнварына кадәр Лениногорск муниципаль районы территориясендә гражданның, шулай ук балигъ булмаганнарны да кертеп, күчемсез мөлкәт объектларына милек хокукы булу (булмау) турында белешмәләрне үз эченә алган белешмәсе;

- Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетының ведомствоара комиссиясенең йорт яшәү өчен яраксыз (авария хәлендә) дип танылган очракта йортны яшәү өчен яраксыз (авария хәлендә) дип тану турындагы бәяләмәсе.

4. Башкарма комитет муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдырудан баш тарту турында Карар кабул итә:

- әгәр хокукка ия булмаган зат мөрәҗәгать итсә (граждан хезмәт торак урынында теркәлмәгән);

- әгәр хезмәт торак урыны Лениногорск муниципаль районы муниципаль милке составына кермәсә;

- документлар тапшырылмаса йә әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакеты тапшырылса;

- әгәр әлеге тармактагы предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә гражданнарның гомуми эш дәвамлылыгы, әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очраклардан тыш, 10 елдан кимрәк булса;

- Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең (хәрби хезмәткәрләренең) гомуми хезмәт дәвамлылыгы, әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очраклардан тыш, 10 елдан кимрәк булса;

- әгәр хезмәт урыны бирелгән граждан башка даими яшәү урынына киткән булса;

- әгәр хезмәт торак урыны бирелгән мөрәҗәгать итүче граждан Лениногорск муниципаль районында гаиләнең бер әгъзасына билгеләнгән исәпкә алу нормасыннан артыграк торак белән тәэмин ителгән булса;

- соңгы биш ел эчендә торак шартлары белә торып начарланса;

- әгәр 01.03.2005 елдан соң хезмәт өчен Торак урын бирелгән мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары социаль наем шартнамәсе буенча торак урынга мохтаҗлар сыйфатында исәптә тормасалар.

5. Муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урынын төшереп калдырудан баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә, баш тарту сәбәбен күрсәтеп, 30 көн эчендә җиткерелә.

Баш тарту турындагы карар суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.

6. Хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турындагы карарлар Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә, ул мөрәҗәгать итүчегә 30 көн эчендә язма рәвештә җиткерелә.

7. Торак урынны махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турындагы карар нигезендә Башкарма комитет Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән торак урынга социаль наем шартнамәсе төзү турында карар кабул итә.

Муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшереп калдыру тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

(Форма)

"Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты житәкчесенә______________________________
__________

(ФИАи)

________________________________________

(ФИАи)

Адресы буенча яшәүче:

_______________________________________

ГАРИЗА

Лениногорск шәһәре адресы буенча урнашкан торак бинаны төшереп калдыруыгызны сорыйм. ____________, ур.__________, йорт ______, корпус _______, фатир. ______, бина. № _ _ _ _ _ _ _ , муниципаль махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннары исәбеннән. Мин һәм Минем гаилә әгъзалары «шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә, атап әйткәндә, «шәхси мәгълүматлар турында»27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәбез. Әлеге ризалык Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган тиешле мәгълүматны яисә күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган документларны саклау сроклары беткәнчегә кадәрге чорга бирелә. Искәрмә. Балигъ булмаган затларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкны аларның законлы вәкилләре имзалый.

Мөрәҗәгать итүче
: ______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча, имзасы)

Хокукка сәләтле гаилә әгъзалары:
1. ______________________________________________________________

(хокукка сәләтле гаиләнең барлык әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, имзалары)